ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.09.2026 с.Старое Дрожжаное № 420

Опека һәм попечительлек секторының административ регламентларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны актуальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 01 августындагы 472 номерлы карары белән расланган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

тәрбияләнүчеләрнең мөлкәте белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү буенча;

балигъ булмаганны эмансипацияләү турында карар кабул итү буенча (балигъ булмаганны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү);

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, гражданнарга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү турында;

баланы (балаларны) матди карап тору өчен опекунга яисә попечительгә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга акча билгеләү һәм түләү буенча, шулай ук опекуннарга яисә попечительләргә, үз вазыйфаларын түләүле башкаручы тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләү;

балигъ булмаган баланың акчалата кертемен алуга законлы вәкилгә рөхсәт бирү буенча;

кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру буенча;

балигъ булмаганныкы булган күчемсез мөлкәтне тартып алу буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча;

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алуга кандидат буларак исәпкә кую буенча;

ятим балалар өчен оешмалардагы балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнарның гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча;

ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яисә) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча;

балигъ булмаган бала (алар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча;

балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен тартып алу буенча алыш-бирешләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча;

опекунга яшәү урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә яшәү урыны буенча опекага алынган затны теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча;

опекунга опекага алынган кешенең торагын наемга тапшыруга рөхсәт бирү буенча;

тәрбиясендәге зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә рөхсәт бирү буенча;

опекунга яисә попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирү буенча;

хокукка сәләтсез балигъ булган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү буенча;

опекунга яисә попечительгә опекага алынган затның Саклык счетыннан файдалануга рөхсәтләр бирү буенча;

суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча;

стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалардагы хокукка сәләтсез гражданнарны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарның гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча;

тәрбияләнүчеләрне стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына стационар хезмәт күрсәтүгә җибәрү турында карарлар бирү буенча.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче                                                                                    Р.И. Мөхәммәтҗанов